2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турындагы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Иске Үзи авылы

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның “18” ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлегендә гражданнар җыены карар итте:

1. Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешегә 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендәге урамнарны кышкы тәртиптә тоту

- Иске Үзи авылының Гагарин, Ленин, Киров, Чапай, Горький, Яшьләр урамнарын ремонтлау (грунтны күтәрү, ком һәм вак таш салу); Чернышевский, Пушкин, Шоссе урамнарын ремонтлау;

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.

- Иске Үзи авылында урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

- җирле халыкның массакүләм ял итү урыны өчен кирәкле товарлар сатып алу һәм коймалар урнаштыру.

3. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру.

- Гагарин, Пушкин урамнарындагы сулыкларны чистарту.

3. Әлеге карарны Иске Үзи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru (http://pravo.tatarstan.ru).

Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Айдова.